ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.06.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1470**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 нче июлендә 1497 нче номерлы карары белән расланган, Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2009 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 381-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 нче июлендә 1497 нче номерлы карары белән расланган, Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә(алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:
«1.2. Әлеге Тәртип максатларында, стационар булмаган сәүдә объекты буларак, инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташу (технологик тоташтыру) булу-булмауга карамастан, җир кишәрлеге белән ныклы бәйләнмәгән вакытлыча корылма яисә вакытлыча конструкция булган , шул исәптән күчмә корылма объекты аңлашыла».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Бауэрга йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев